# Бәйрәм бите

## ФЕВРАЛЬДӘГЕ БӘЙРӘМНӘР:

**8 февраль** — Россия галимнәре көне. Бүген үзенең һөнәри бәйрәмен рус галимнәре бәйрәм итә. Алар хакына гына Россия шулай алга киткән! Ломоносовлар гына түгел, безнең якта да байтак алар!

**10 февраль** — А.С.Пушкинга багышланган көн

**14 февраль** — Изге Вәли көне. Яраткан кешеләргә мәхәббәтеңне күрсәт, ярат!

**17 февраль** — официаль түгел, әмма бик матур бәйрәм — Яхшылык көне. Бүген барсына да яхшылык теләә, изгелекләр эшлә, дускаем!

**21 февраль** — Туган тел көне. Бу вакыйганы мәктәптә зурлап оештырдылар.



**23 февраль** — Ватан саклаучылар көне.

**26 февраль** — Кунакчыллылык һәм күңел ачу көне. Иң шат бәйрәм булыр, миңа калса! Шулай ук без үзебезнең яраткан укытучыларны, аларның туган көне белән котлыйсы, сәламәтлек, бәхет-шатлык, тынычлык һәм сабырлык телисе килә. Хөрмәтле Шайдуллина Илмира Салиховна, Габидуллина Гөлшат Илгизовна, Сәрия Кәшифовнабыз, туган көнегез белән!

Сүз уңаеннан, 7-23 нче февральдә барган Кышкы Олимпия Уеннарын да карадык без. Россия бу Уеннарда 1нче урынны алды! Афәрин!

## Конкурс

### Моңлы сыйныф




Мин 6 «А» сыйныфында укыйм. Сыйныф җитәкчебез — Харисова Илсөяр Мөҗәһит кызы.Бүгенге көндә безнең сыйныф артык тыныч булмаса да бик шаян һәм шат күңелле. Шуның белән ул миңа ошый да инде. 6нчы сыйныфымда минем иң якын дусларым да табылды, бу — Хасаншина Резидә, Маторина Настя. Классыбыз моңлы. Сабиров Илдарны сез беләсездер инде, ул атаклы мәктәп җырчысы. Гармунчы һәм баянчылар да күп бездә. Илдар Баһманов һәм Булат Сөләйманов гармунда шәп уйныйлар. Зөһрәбез дә өйрәнә. Шайхулова Адилә фортепианода уйный, музыка мәктәбен быел бетерә инде. Ә Әмир — сыйныфыбызның мактаулы кешесе. Математиканы әйбәт белә, дзюдо белән шөгыльләнә, шул вакытта сулагай да әле! Чибәр кызлар мәктәбебездә байтак. Фәсхиева Әдилә, Исламгулова Розалия, Шайдуллина Айгөл, Хасанова Әдиләләр иң чибәрләре. Барыбер, бөтенесе дә бик матур, үзенчәлекле булуы белән җәлеп итә!!!

*Әлмиева Резидә, редколлегии әгъзасы*

## Ял итү бите

### 6 «В» - ну просто КЛАСС!

Ребята дружные у нас,
Всегда милы, добры друг к другу,
Подать в беде готовы руку.
Командир у нас Ленар,
Аделина песенки поёт
И на сцене выступает,
Весь народ наш развлекает
Все мы учимся, играем,
Любим праздники справлять.
Грусти мы совсем не знаем –
Просто некогда скучать!

*Гуля Эрниязова*, 6 «В».

### Внимание! Конкурс!

Стартует новый конкурс! Что ты хочешь сказать про свой класс? Весёлый, непобедимый, быстрый. Наверное, у тебя уже выстроился ряд идей по поводу сочинения. Присылайте сочинения про свой класс! Обращаться в 307 кабинет (кабинет тат. языка и литературы), членам редколлегии.



Мәктәп газетасы "Тамчы"

**Редколлегия**: Әлмиева Резедә, Гарифуллина Әдиля, Гилфанова Раилә, Шәйдуллина Айгөл.

**Шеф редактор**: Шәйдуллина Ландыш Камил кызы.

► Мәктәп газетасы айга бер тапкыр чыга.

► Мнение автора может не совпадать с мнением редколлегии.

► Газетадан материал алу сәбапле, сылтамасын күрсәтү мәҗбүри.

► Рубрикалар: "Медицинская аптечка", "Новостная лента", "Творчество юнкоров" яки "Иҗат бите", "Минем тормышым", "Галерея", "interview".

► Элемтә редколлегия әгъзалары, шеф-редактор (307 кабинет) һәм электрон почтадан (rese_almee@mail) үтәлә.



*Тел – кешенең рухи көзгесе.*



# Тамчы

МБОУ "2 номерлы Җәлил урта мәктәбе"нең мәктәп газетасы. Февраль (25.02.14)

Анонс

"Мин татарча сөйләшәм!" акциясенә старт!

**Редколлегия сүзе—1, 2 битләр**

Бәйрәм бите — 8 бит

Премьералар турында — 2 бит

Интервьюлы февраль — 3 бит

ВАТАН саклаучылар көне

Лунный кот — 4 бит.

Минем солдат буласым килә — 6 бит

Номерның темасы: туган тел

## Редколлегия сүзе.

Сәлам барысына, барысына — укучыларга, укытучыларга, бу газетаны һәрбер укучыга! Сезне мәктәп газетасы сәламли. Бүгенге номер — беренчедән, "Мин татарча сөйләшәм" акциясенә, икенчедән, татар теленә, өченчедән, иксез-чиксез истәлекле бәйрәмнәргә һәм даталарга багышланган. Сез февраль аеның озак көтеп алынган газета номерын укыйсыз.



Бу айда без Изге Вәли көнен билгеләп үтәбез, Ватанны саклаучылар көне дә—шушы айда. Ватан саклаучылар көне алдыннан бездән сезгә бүләгебез дә бар! Сюрпризыбыз — Шәйдуллина Айгөлнең әтисенә адресланган шигыре. Син аны 5нче биттә карый аласың. Знче февральдә безгә студентлар кунакка килделәр (***фотода***). 15 февраль датасы да аеруча мөһим. Бу



көнне Россия интернационалист сугышчыларны искә ала. Сугыш булмаса, татар халкының каһарман улы Муса Җәлил дә үзеннән соң нинди зур иҗади мирас калдырыр, әдәбият һәм сәнгатьне үстерү юнәлешендә күпме эшләр башкарыр иде?! Үлгәннән соң да яшәүче бу батырның туган көнен без нәкъ февраль аенда билгеләп үтәбез. Муса Җәлилнең туган көненә багышланган митинглар, шигырь сөйләү конкурслары, викториналар узды. 15 көнне тагын бер кешенең дөньяга килгән көне — Сарман егете, көчле тавышлы җырчы Илһам Шакировның туган көне. Газетада сез яңалыкны да күрерсез — Домнина Даринаның "Лунный кот" әсәре. Рәхәтләнеп укыгыз, дуслар!

* * * * * * * * * * * * * * * * * *

**10-15 февраль көннәре арасында Сәламәтлек атнасы үтте.**

**2014 ел — Математика елы. Ә математика атнасы — 17 февральдән башлап 22нә кадәр барылган атнада 19 февраль 6нчы сыйныфлар арасында математик КВНнар оештырылдылар, фәнни эшләр конкурсы да беркемне дә игътибарсыз калдырмады.**

**10 февраль Бөтенроссия күләмендәге дәрес узды. Ул "Сәламәт балалар — сәламәт гаиләдә" исемле. Бу дәрескә спорт сөюче Пименовлар гаиләсе, физик тәрбия укытучысы Ихсанов Эдуард килде. 6 Б укучысы Нуретдинов Илдар Сочи-2014нең формасын күрсәтте.**

**19нчы февраль «Алло, без талантлар эзлибез!» конкурсының гала-концерты булды. Ул бик кызык һәм мавыктыргыч иде.**

**21 февральдә 2нче санлы Җәлил мәктәбенә шагыйрьләр килде.**

# ТУГАН ТЕЛЕМ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАМ

Эта тема посвящена моему родному языку — татарскому. Татарский язык, наряду с русским, является государственным языком Республики Татарстан. На татарском языке издаётся учебная, художественная, публицистическая и научная литература, выходят сотни газет и журналов, ведутся радио- и телепередачи, работают театры. Современный татарский язык в своём становлении претерпел множество изменений, сформировался из смешения древне-булгарского с кыпчакскими и чагатайскими диалектами тюркских языков. А сегодня мы решили испытать и наших учеников и учителей… Нужен ли татарский? Зачем он нужен? Что он для нас значит? И на этот вопрос многие отвечали на русском…

## “Мин татарча сөйләшәм” акциясе турында

**Раиля Гильфанова**, член редколлегии: “Основными целями акции "Мин татарча сөйләшәм" является поддержка реального функционирования татарского языка в городе, расширение границы его использования. Впервые акция была проведена в 2005 году по инициации креативного движения нового поколения "Үзебез". В современном мире народ имеет шансы на сохранение и развитие. А как народ может функционировать без своего языка, который является одним из ключевых элементов национального самосознания человека.

“Мин татарча сөйләшәм” дип торган сөйкемле “смайлик”ны хәзер Татарстанда гына түгел, Татарстаннан читтә дә беләләр. Бу — татар теленең дәрәҗәсен күтәрү, куллану даирәсен киңәйтү, яшьләрне милли мәдәниятқә тарту максатыннан үткәрелүче акция. 2005 елда башланып киткән акциянең кысалары быел күпкә киңрәк. Мәсәлән, акциянең бер өлешен татар журналистлары башкара. Һәр журналист үз “шефлыгына” алган оешманы татарчалаштырга. Кыскасы, русча язулар янында татарчасына урын табылуга омтылабыз.

## “Өч аяклы ат”

Бер көнне, әдәбият дәресендә “Өч аяклы ат” фильмын карадык. Ул безгә бик-бик ошады! Бу фильм Айдар Хәлим әсәре буенча төшерелгән икән. 2008нче елда Алтын Мөнбәр конкурсында катнашкан. Режиссёры — Нурания Жамали. Әлеге драма үз таянычын югалткан, кыргый җанварлардан зарар күргән, аксак атка охшый башлаган халык турында... Сез дә карагыз, җәлләмәссез. ***Әлмиева Резидә, 6 “А”.***

**Игътибар**, кадерле дуслар! Март санында мәктәп газетасында экология турында иншалар урын ала. Шулай ук үзегезнең рәсемнәрегезне, шигырьләрегезне, мәкаләләрегезне безгә бирергә кыенмагыз! Безнең белән элемтә турында 8нче биттә укырсыз.

## *Сүз ирәгә*



***Фәсхиева Айгөл**, 11 “Б” сыйныфы*: “Минем яраткан команда, волейболчылар-ы-ы-м! Мин безнең гамьсез-кайгысыз, искиткеч кызыклы көннәрне сагынам. Бүтән бу булмый да инде, кызлар! Без бик күп нәрсәне җинеп чыктык. Проблемаларны белмәүдән вакытны да кызык үткәрдек. Без бик борчыла идек тә, ә аннан соң бер-беребезне тынычландыра идек. Тиздән без инде таралышабыз, яраткан кызларым минем! Рәхмәт сезгә, кадерлеләрем!!!”

**Игътибар, кадерле укучылар!** «Минем идеаль мәктәп» бәйгесенә нәтиҗәләр: -

Әлмиева Резидә, 6 «А» - 1 урынны алды.

2 урын— Маторина Анастасия

3 урын— Алина

Призы зрительских симпатий: Хәсаншина Резидә, Арсланова Гөлназ.

## Наши пожелания

### Безнең котлауларыбыз

**Хәсәншина Резидә**, 6нчы А : Ватан саклаучылар көнен безнең гаиләдә зурлап оештыралар. Мин дә бу бәйрәмнәргә бүләк ясарга яратам, аларны бүләк итәм. 23нче февральдә минем иң яраткан кешеләремне котлыйсым килә — энем Станислав, абыем Рөстәм, әтием Флюрны… Мин аларны яратам, хөрмәт итәм һәм аларга уңышлар телим!

**Арсланова Гөлназ**, 6 «А» : Мин әтиемне, абыемнарны һәм бөтен-бөтен ир-атларны 23нче февраль белән котлыйм!

**Гарифуллина Аделя**, 6 «Б»: Люблю моих одноклассников, папу! Именно их я бы хотела поздравить с Днём Защитника Отечества! Я желаю им, во-первых, здоровья, удачи, успехов в учёбе, и главное, оставаться такими же весёлыми и задорными!

**Салимзянова Алсу**, предводитель юнкоров, в декрете: Хочу поздравить всех людей мужского пола, пожелать им нескончаемой силы, успеха, здоровья, терпенья!

## Супер-Яңалык!

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы һәм «Тамчы»ның редакторы Шәйдуллина Ландыш Камил кызының *белем.ру* сайтында **«Ел ресурсы»** исеменә лаек булган, Р. Фәхреддинга багышланган язмасы чыкты! Без Ландыш апаны чын күңелдән котлыйбыз, аңа тагын да уңышлар телибез!






**Команда КВН «Онлайн».** На фото (слева-направо): Настя Якимова, Натя Иванова, Румиль Ихсанов, Эльмира Имаева, Динар-Тимерзянов, Диана Хамзина.

## Редколлегия сүзе

21нче февральдә бөтен дөньяда Халыкара туган тел көнен билгеләп үтелә. Шул уңайдан татар теле өчен борчылып, аны яклауны, милли үсеш өчен тигез шартлар булдыруны таләп итеп татар акцияләре бара. Шуларның берсе, инде берничә ел бара торган канатлы “Мин татарча сөйләшәм!” проекты. Февраль аенда башланган старты буенча, зур җаваплык тотабыз сыман без! Олимпиада утын тотып алучылар кебек. Татар телен сакларга тиешбез, ич! Шулай итеп, без, Гарифуллина Әдилә, Әлмиева Резидә һәм Гыйлфанова Раилә, Шәйдулина Айгөл һәм шеф-редакторыбыз Шәйдулина Ландыш Камиловна белән 307 нче кабинетта акциянең планын үзләштертерергә булдык, соңрак укытучыларны, директор урынбасарларын да чакырырга иде. Хәер, өлкән сыйныфларга татар теленең проблемаларны Ландыш Камил кызы аңлатты инде. Без бик күп бәйрәмнәр, викториналар, концертлар, конкурслар оештырдык. Экспериментларны уздыру тагын да кызыграк! Беренчедән, без Татарстанда эшләнгән ашамлыкларны тикшердек. “Татар” ашамлыкларында татар телендәге белешмә бик күренмәде. Россияләп булганнары, белорус һәм казак теле бар, вәт кызык! Икенчедән, җәмгыятьтә татарча сөйләшәләрме, шуны тикшердек. Урта һәм өлкән яшьтәгеләр туган телендә чиптачиста сөйләшә, ә укучылар оялаларны әллә?! Газета конкурслары да эзсез калмады. “Минем идеаль мәктәп” бәйгесендә иң матур һәм кызыклы мәкаләләрне тупладык, ә “Минем класс” исемле конкурс әлегә дә үз тормышы белән кайный. Бер айга инде 5 искиткеч язманы укыдык. Материал күп булу сәбәпле, бөтенесен дә газетада урнаштырып булмады. Интервьюлар да күп алдык. Шуңа күрә, клавиатурадан бармакларны алмый азапланып, бу газетаны чыгардык та!


Туган телен кадерләгән халык кына кадерле булыр.

*Р.Фәхреддин*

2 нче февраль безнең яраткан Эльмира апа Имаеваның туган көне! Чын күңелдән аны туган көне белән котлыйсы килә! Корычтай сәламәтлек, ак бәхетләр, шатлыклы мизгелләр, күп-күп елмаюлар телибез сезгә, Эльмира апа!

**Белгәнебезчә, быелдан мәктәпне гел “биш”легә тәмамлаучыларга “кызыл” аттестатлар гына тапшырачаклар. Хәзер алдынгы укучыларга бирелгән алтын мәдальләр бирелми. Югары уку йортына кергәндә БДИ нәтиҗәләре генә исәпкә алына, медальләрнең практик әһәмияте югалды.**
**“Ялкын”**

## Премьералар турында...



**Кино:** Воровка книг: 1939 елдагы сугыш башлангач, Лизель тәрбияче ата-анасында яши. Аларда китап укырга өйрәнә, үзенә шатлык китерә торган китапларны ул урлый башлый. Ахыр чиктә, болар Лизельның шәхси тормышын тәшкил итә.

**Моноспектакль:** Казандагы Качаловский театрының яңа сезонын Марина Цветаева шигырьләре буенча моноспектакль ачып җибәрә. Моноспектакльнең баш роле: Светлана Романова.

**Фестиваль**: Быелгы XXXII Шаляпин халыкара опера фестивале 2-18 февральдә үтә.

**«ЯЛКЫН» журналы конкурс игълан итә!** Бу конкурста һәрбер мәктәп укучысы катнаша ала. Моның өчен үз профессиясенең (әшче профессия турында сүз бара: слесарь, комбайнчы, тегүче, электрик, пешекче һ.б.) остасы булган абый-апаның эш урынына барып, аның профессиясе, эш урыны, эшләү рәвеше, бу профессиянең башкарлардан ни белән аерылып торуы, үзенчәлекләре турында репортаж ясарга кирәк. “Кайнар нокта”дан фотолар төшереп алырга да онытмагыз!

## Минем солдат буласым килә

# С 23 ФЕВРАЛЯ!



Бүгенге тыныч тормышта яшәгәнебез өчен, кешеләр илне саклаучыларга рәхмәтле. Без төннәрен рәхәтләнеп йоклыйбыз, тынычлап эшлибез, тынычлап укыйбыз, эшлибез. Ә солдатлар, безнең җиребезгә беркем дә явыз ният белән яшеренеп кермәсен дип, көне-төне сакта торалар. Мин алар белән горурланам, аларга охшарга тырышам, алар кебек кыю, батыр, тәвәккәл буласым килә. Минем әле тагын әтигә дә охшыйсым килә. Ник дисезме? Белмәсәгез, хәзер әйтәм: минем әтием Әсәдуллин Данис ...... улы – герой. Ул - Әфган сугышында катнашкан солдат. Җитди, төгәл, түземле, тәвәккәл, таләпчән һәм бик көчле булганга, мин аны бик яратам һәм хөрмәт итәм. Әтием миңа һәрвакыт: “Армия – егетләрне чын ирләр ясый торган мәктәп ул, “- дип сөйли.



Әтиемне армия сафларына көз көне озатканнар. Галия әбием аны елап озатып калган. Ул көннәрне әтием болай искә ала: ”Әй барабыз, барабыз. Шундый ерак барабаз кебек тоелды. Татарстаннан чыктык, зур самолет безне күккә алып менде. Илебез болытлар арасында бер нокта кебек кенә булып калды.Җирдә дә, күктә дә уем туган ягым белән булды. Очып барган кош артыннан, кайтыр идем, дип уйлап куйганым хәтердә. Аннан инде безгә солдат шинелен кидерделәр, машинага утырттылар. Ерак илгә, безгә таныш булмаган таулы-ташлы бөтенләй чит гореф –гадәтле Әфган җиренә аяк бастык, улым...

Туган илемне, еракта калган газиз әнкәм, туган-тумачаларымны бик сагындым мин. Туган илкәемне, дусларымны, яраткан Азнакай якларын күрәсем, көмештәй сулы чишмәбезнең салкын суларын эчәсем килде...

Без ят җирләрдә йөрдек, безнең баштан авыр хәлләр уздылар.Дусларым яхшы булып чыкты. Дуслыкның кыйммәтен армиядә, яу кырында бик яхшы аңлыйсың икән. Дошман уты аяктан екканда, авырлыклардан сыгылганда, бер-беребез терәк булырга тырыштык, тик менә юл читендә үлеп яткан дусларыбызга гына ярдәм итә алмадык. Аларга кара ташлар истәлек булып калдылар. Шундый ташларны күргән саен һәрберебезнең күңеленә:"Илләребезгә исән–имин кайта алмасбыз микәнни" дигән куркыныч уйлар килде.

Улым, мин ул вакытларны искә төшерү бүген дә авыр. Безгә бормалы– бормалы, тау-ташлы, упкынлы юллардан узарга туры килде. Шофер кешегә икеләтә авыр, чөнки ул әллә ничә солдат гомере өчен дә җавап бирә. Тент белән капланган машина кузовындагы үзем кебек үк яшь кенә егетләрнең миңа булган ышанычын аклауның авырлыгын белсәң иде син, улым...

Галия әбиең, минем әнием, гомере булсын дип теләгәндер инде, аның изге догалары саклаган мине... Шундый утлы чолганышлардан, үлем



тозакларыннан исән чыгуны мин әнинең изге догаларыннан гына булгандыр дип уйлыйм.

Туган илгә бик кайтасым килгәнгә, йөрәккәем ашкынганда, мин хат яза идем. Кәгазь битенә: ”Үземнең кайда икәнемне аңлатып хат язарга утырдым әле. Гаскәр төре - автобат. Иртәгә иртәнге 4тә чыгып китәбез инде. Хатларны ешрак язарга тырышыгыз, чөнки төнлә машина кабинасында кунганда “хат килгән икән”дип төш күрдем", - дип язган хатлар бүген дә әбиеңнең сандык төбендә саклана.

Калдырып, үзебезнең Илбәккә кайтуны күпме көттем мин?! Авылның салкынча кичләрен, алсу таңнарын, җиләс көннәрен, карлы кышларын сагындым. Хатларымда шул турыда язганмын, төшләрем турында сөйләгәнмен.

Аллага шөкер, исән-сау кайттым, улым. Язмыш мине әниең белән очраштырды. Син тудың. Сез мина яшәү көче бирәсез. Улым, сиңа сугыш күрергә язмасын, безнең җылы кочагыбызда үсеп, укып чыгып, үзең теләгән һөнәр сайлап, тыныч тормышта яшәргә язсын иде сиңа.

(**Ахыры—5нче биттә**)



Интервью от Зухры Загировной

## interview

# Мечты сбываются !

На этот раз мы взяли интервью у нашей новой учительницы физической культуры Хабибуллиной Зухры Загировной. Именно ей мы задали наши каверзные вопросы.

**ДОСЬЕ**

**Хабибуллина Зухра Загировна**

Родилась в 1994 году

**Какой ВУЗ вы закончили?**

Я окончила Альметьевский техникум физической культуры.

**Какая мечта была у вас в детстве?** Главная мечта детства — стать учителем. И она сбылась!!!

**Что для вас значит победа?**

Победа приносит радость, ощущение свежести и открывает тебе новые возможности.

**Что вы любите делать в свободное время?** Люблю читать книги. У спортсменов не бывает свободного времени!





**Почему вы выбрали спорт?**

Быть спортсменкой — важная честь. Ты защищаешь свою команду, учишься жизни, дружбе! Особенно это бывает на соревнованиях.

**Каких наград вы удостоились?**

Их очень много: по лыжному спорту, по теннису.

**Что больше любишь: фотографировать или фотографироваться?**

Фотографировать.

**Зухра Загировна желает всем мужчинам нашей школы здоровья, удачи, хорошего настроения, и больших успехов в учёбе! С 23 февраля, дорогие ученики, учителя и работники школы!**

**Арсланова Гульназ и Шайдуллина Айгуль, 6 «А»**



Интервью от врача

Узнаём секреты зимы!!!

## interview



1. Гильфанова Римма Римовна, 40 лет.
2. Училась в Бугульминском медицинском училище.
3. Работает медсестрой функциональной диагностики.
4. **Что такое хорошее настроение для вас?** Хорошее настроение - это когда все в порядке, нет тревог и волнения.
5. **Чем для вас характерно правильное питание?** Правильное питание — это сбалансированное питание.
6. **Чем нужно питаться зимой?** Зимой старайтесь кушать цитрусы (мандарины, апельсины, лимоны) и овощи, а летом ягоды и зелень. Употребляйте много жидкости, особенно воду.
7. **В зимний период бывает ухудшено здоровье ученика. Как предотвратить это?** В зимнее время года надо одеваться теплее, держать ноги в тепле.
8. **Как относятся к врачам люди? И на каком языке больше говорят: татарский или русский?** Люди уважают врачей, очень любят, многие приносят улыбки, смешат, дарят подарки! Очень добросердечные люди в Джалиле! Говорят больше на русском, пожилые же люди общаются на татарском языке.
9. **Чем вас радует современная медицина?** Современная медицина пригодна для меня тем, что сейчас можно вылечить различные трудноизлечимые болезни, сделать качественные операции, в том числе и на сердце. Радуют возможности, которые предоставлены им в сегодняшнее время.



**Узнала важные советы этой зимы ученица 6 «В» Гильфанова Раиля**

**В преддверии 23 февраля — Дня Защитника Отечества, хотела бы поздравить своего папу Линара и брата Рамиса!**



(*Ахыры*)

Дөньябыз имин булсын, сугыш авазлары кабатланмасын,”- ди минем этием. Шушындый этием булганга, мин бик бәхетле. Ватанны саклау - һәр кешенең, бигрәк тә ир-егетләрнең, иң изге бурычы. Әтием аны намус белән башкарган. Җәлил беренче мәктәбендә ачылган ”Батырлыр һәм геройлар“ күргәзмәсендәге фотосы шул хакта сөйли. Мин дә үземә йөкләнгән бу бурычны төгәл үтәрмен дип уйлыйм. Безнең күгебез гел аяз, чишмә суларыбыз саф, аналарның йөзе якты, сабыйларның йокысы татлы булсын өчен, минем дә этием кебек солдат буласым килә.

***Асадуллин Алмаз***,
икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укучысы




## Әтиләребез, бабаларыбыз турында.

Минем бабамның әтисе сугышта хәбәрсез югалган. Аны корал ясарга дип заводка алган булалар. Карт бабам сугышка киткәндә бабама ике генә яшь була. Шул китүдән карт бабам кайтмаган, бабай аны күрә алмаган. Карт бабамның исеме хәзер Хәтер китабында.

**Аяз Вәлиев, 5 нче в сыйныфы**



Армия, солдат сүзләрен ишетсәң, батыр илне саклаучылар күз алдына килә. Элек-электән ир-егетләр армия сафларында хезмәт иткәннәр. Алар-га хөрмәт белән, сокланып караганнар. Бөек Ватан сугышы елларында күпме ир-егетләр башла-рын салганнар, хәбәрсез югалганнар. Әфган сугышында да, халыклар тыныч яшәсен өчен, солдатлар гомерләрен җәлләмәгәннәр. Күпме егетләр дошман уты астында калып, таулардан әйләнеп кайт-маганнар. Алар барысы да кемнеңдер кадерле улы, әтисе, ирләре булганнар бит.

Минем дә бабайларымның этиләре Бөек Ватан сугышында үлеп калганнар. Без аларны мәңге онытмыйбыз. Минем эти-ем дә абыйларым да армия сафларында булганнар. Мин алар белән горурланам. **Алинә Әхмәтҗанова**

## ӘТИЕМ – ГОРУРЛЫГЫМ

Әтием минем хезмәт иткән
Тын океан ярында.
Тынычлыкны тәэмин итеп,
Торган ул чик сагында.

Әтиемнең солдат чакта
Төшкән рәсемнәре күп.
Матрос киеме этиемә
Үлчәп тегелгәндер кук.

Ак тасмалы якасына
Дуслар телэк язганнар.
Алар барысы этиемнең
Күңелендә калганнар.

Камчатка хатирәләрен
Әти безгә еш сөйли.
Рәсемнәрне караганда
Эчтән жырлар да көйли.

Ул сагынып искә ала
Су асты коймәләрен,
Инләп-буйлап океанны
Өйрәнеп йөргәннәрен.

Ни дисәк тә, этиемдәй
Хезмәт итүче сирәк.
Яхшы матрос булу өчен
Өч еллык хезмәт кирәк!

Шундый әтием булганга,
Мин бик тә горурланам.
Әтиемдәй кыю, батыр
Булырга хыялланам.

Әтиемә телэгем бар
Бәйрәм алды көнендә:
Әти, шундый яшь, матур бул
Һәм авырма син бер дә.



**Шәйдуллина Айгөл**, 6нчы «А».

Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел.
Икесе дә - безнең өчен
Иң кирәкле татлы тел!



## Лунный Кот!

Глава1 Появление

Луна ярко сияла на небосклоне, освещая озеро, которое было в чаще огромного леса окруженного горами. Людям же там находится в окружении этих гор, но никому не суждено было туда попасть! Возле луны резвились звёз-ды. Одна была особенно яркая. Она часто наблюдала за тем, что происходит в низу и любопытство взяло вверх.
- Мама, можно вниз на Землю, -эта звёздочка была осо-бенно яркая, потому что была дочерью луны.
— Хорошо, но возьми с собой это,— луна дала её кулон.
Звёздочка начала спускаться вниз. Она очень много раз видела котов и поэтому приняла образ кота. Еле касаясь земли она спрыгнула с неба. Её шерсть лоснилась и была цвета луны, а полоски цвета неба . На шее её висел лун-ный кулон, а на лбу звезда такая же ослепительная и светлая, как и была звездочка. Так она спустилась на Зем-лю. Там написано "Людям было интересно, что же...." .

Глава 2. Лунное племя Кошечка проснулась от яркой вспышки света. Она подняла голову и огляделась: все спали. Она поднялась на лапы и увиде-ла угасающее мерцание вдали. Аккуратно вылезев из пещеры белая кошечка с рыжими лапками и спинкой бросилась в кусты на встречу сиянию. Оно вывело её к озеру, где она увидела белого котика с синими полоска-ми. Подошла поближе: котик был примерно такого же роста, как и она. - Кто ты?, - спросила наконец кошечка. От неожиданности полосатый котик даже под-прыгнул. - Я..я.... Я звёздочка!, – мяукнул тот.
- Что?, – не поняла она.
- Я звёздочка, спустилася с неба из любопытства.
- Значит у тебя нет имени?,- полосатый котик призаду-мался.- Нет! А как тебя зовут?
- Я Огнелапка.- проурчала кошечка.- Твоя шёрстка лун-ного цвета. Давай я отведу тебя в своё племя.
- Я не знаю. А что это за племя?
- Не бойся. А племя моё – Лунное! – промурлыкала ко-шечка.
Огнелапка повела его в лагерь Лунного племени. Они вошли через кусты и увидели поджарую белую кошку, которая ходила взад-вперёд. Увидев Огнелапку, она ки-нулась к ней.
- Огнелапка, где ты была?- зашипела она и с яростью лиз-нула её лоб.
- Не беспокойся, Звёздная Буря. Я нашла его около Лун-ного озера,- и она махнула хвостом в сторону полосатого котика и рассказала историю, как она его встретила.
- Хмм… Посмотрим, сможешь ли ты пройти испытание, а пока идите отдохните,- кошка ушла и Огнелапка со сво-им спутником пошли в небольшую пещерку.
Огнелапка разбудила котика и они пошли к выступу в скале и услышали голос предводительницы, - пусть все коты соберутся на общее собрание под Лунной скалой. Коты начали медленно вылезать из пещёр и оборачивать-ся на белого котика. Возле Звёздной бури сидел крапчато рыжий кот.

Этот рассказ написала **Домнина Дарина**. В следующем номере ты узнаешь продолжение этой истории…

## Алар - мәктәбем горурлыгы

Мәктәбебез диварына эленгән мемориаль элмә такталар безнең барыбызга бу уку йортының куркыныч Әфган сугышында батырларча һәлак булган укучылары булуы турында хәбәр итәләр. Еллар узган саен, бу сугышның кайтавазы тоныкланса да, ул онытыла алмый. Яу кырларында һәлак булган егетләрнең әниләре, туганнары күңелендә сугыш китергән газаплар беркайчан да жуелмас. Бу хакта зиратлардагы кабер ташлары, диварга эленгән әнә шундый элмә такталар һәрчак искәртеп торачак, уйландырачак. Аларга чәчәкләр салган саен, Миннекаев Рифкать абый белән Притула Сергей абыйга без баш иябез, рәхмәтебезне әйтәчәкбез. Хәрби бурычларын үтәгәндә яшь-яшь килеш һәлак булган бу батырлар мәктәптәге барлык укучылар өчен гел батырлык үрнәге булачаклар. Сугыш кырыннан 14 иптәшен алып чыгып, үзе каты яраланган Рифкать абый белән ничек горурланмыйсың?! Бу яраларының үлемгә китерәчәген аңлыйсың бит ул. Югыйсә, качып, дошман һөҗүменең тынып торган чагын да көтә алыр иде. Тик ул качып ятарга теләми. Үз гомерен башкаларныкын коткару өчен кызганмый. Шушы батырлыгы өчен Р.Миннекаев үлгәннән соң Кызыл Йолдыз орденына лаек була. Бу зур бүләк үзенә тапшырылган "Батырлык өчен" медале белән бергә әнисе Динә апа кулында саклана.

Рифкать абый турындагы истәлекләрдән без аның спорт яратканын, мәктәптәге эшләрне башлап йөргәнен беләбез. Ул үти алмаган бирем булмаган, нәрсәгә тотынса, шуны жиренә житкереп башкарган. Сабырлык, жаваплылык, авыр чакта ярдәм кулы сузарга әзер булу – кеше өчен иң кирәкле сыйфатлар, минемчә. Рифкать абый Миннекаев шундый булган да.

Сергей абый Притуланың этисе үлгәндә аңа бары 3 кенә яшь булган. Шуңа күрә ул тормыш авырлыкларын бик бәләкәй чактан ук җиңеп үскән. Аның әнисенә, карт әбисенә олы терәк буласы килгән. Сергей абыйның бернича сакланган хаты бар икән. Аларда ул үзенең бик нык сагынуы турында язган. Әнисеннән өйдәге хәлләрне сораган, кайткач эшлисе эшләре хакында хәбәр иткән. Нинди матур хыяллары булган аның! Сугыш бу хыялларның барысын челпәрә китергән, ә егетне тау-кылар арасында йөрергә мәжбүр иткән. КамАЗ машинасында корал ташыган Сергей абый үлем белән әллә ничә тапкыр күзгә-күз очрашкан. Очрашкан, тик каушап калмаган, юлын дәвам иткән.

Сергей Притула 1985 нче елның мартында дошманнар безнең гаскәрләрне утка тоткан чакта һәлак була. Аны 2 нче апрельдә Җәлил зиратында жирлиләр.

Сергей абыйның әнисе Ләйлә апа Әхмәтҗанованың мәктәпкә улы белән бәйле бик күп фоторәсемнәр бүләк иткән. Бер рәсемнән елмаеп карап торган көләч йөзле, бик матур Сергей абыйның алдагы рәсемдә табутта ятуына ышанасы гына килми.

Сергей һәм Рифкать абыйларның исемнәре югалмасын. Әфган сугышының алар кебек үк куркусыз барлык геройларын онытмыйк.

Айгөл Шәйдуллина, 6 а







# М. Җәлил шигырьләрен сөйләү конкурсы









13нче февраль безнең мәктәптә Муса Җәлилнең рус теленә тәрҗемә ителгән шигырьләрен сөйләү буенча конкурс үтте. Бу бәйге 5-8нче сыйныфлар арасында иде. Жюри Талипова С.А., Садыкова И.З., Гордюшина Л.З.дан торды. 5б дан Салихова Айсылу, 7 а дан Сагындыкова Карина һәм 8 а дан Нургалиева Ландышларның чыгышлары жюрига бик ошады. Гомумән, укучылар конкурска ныклы әзерлек белән килгәннәр иде.













Бәйгедә без Муса Җәлилнең тормышы буенча сорауларга җавап бирдек, күбрәк аның сугышка һәм мәхәббәткә багышланган шигырьләрен сөйләдек. 3 кеше “Варварство” диелгән шигырьне ятлаганнар. Бу — Домнина Дарина, Гарифуллина Әдилә, Калимулина Диләрә. Диләрә шигырьне шулай бирелеп сөйләде ки, сугыштагы авыр тормышка битараф кала алмыйсың, елап җибәрәсең… Конкурс бик кызык үтте, без Муса Җәлил тормышына һәм иҗатына тагын бер тапкыр сокландык, шулаймы?